**РАСЛЫЙМ**
ДАҺБУ "Казан педагогика көллияте" директоры
__________ А.Г.Залялова
"16" февраль 2023 ел

**2023 елда 44.02.01 "Мәктәпкәчә белем бирү", 44.02.02 "Башлангыч сыйныфларда белем бирү" белгечлекләре буенча абитуриентлар өчен сынаулар үткәрүгә куелган таләпләр**

1. Урта һөнәри белем бирү программалары буенча 44.02.01 "Мәктәпкәчә белем бирү" һәм 44.02.02 "Башлангыч сыйныфларда белем бирү" белгечлегенә укырга керү сынаулары, кабул ителгән гаризалар нигезендә, төп гомуми һәм урта гомуми белеме булган абитуриентлар өчен үткәрелә.

2. Керү сынаулары 44.02.01 "Мәктәпкәчә белем бирү" һәм 44.02.02 "Башлангыч сыйныфларда белем бирү" белгечлеге буенча урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программаларын үзләштерергә әзер булуларын билгеләү: укырга керүчеләрнең мотивацияле һөнәр сайлаулары, актив гражданлык позициясе, балалар белән эшләү омтылышлары һәм сәләтләре, социаль әһәмиятле эшчәнлектә катнашуның беренчел тәҗрибәсе булу-булмавын ачыклау максатыннан үткәрелә.

3. 44.02.01 "Мәктәпкәчә белем бирү", 44.02.02 "Башлангыч сыйныфларда белем бирү" белгечлекләре буенча керү сынаулары профессиональ буларак үз-үзеңне тәкъдим итү (һөнәри яктан үз-үзеңне презентацияләү) һәм иҗади биремне үтәү рәвешендә үткәрелә.

4. 5 минут вакыт арасында телдән кыска тематик хикәя рәвешендә үз-үзеңне тәкъдим итү (презентацияләү) абитуриентның телдән сөйләм дәрәҗәсен һәм культурасын бәяләргә мөмкинлек бирә.

44.02.01 "Мәктәпкәчә белем бирү" белгечлеге өчен үз-үзеңне тәкъдим(презентацияләү) итү темасы: "Ни өчен мин тәрбияче һөнәрен сайлыйм?" . 44.02.02 "Башлангыч сыйныфларда белем бирү" белгечлеге өчен үз-үзеңне тәкъдим итү темасы: "Ни өчен мин башлангыч сыйныф укытучысы һөнәрен сайлыйм?»

Үз-үзеңне һөнәри яктан тәкъдим итү (презентацияләү) вакытында абитуриент ни өчен педагогик белгечлек буенча укырга теләвен дәлилләргә, киләчәк һөнәри эшчәнлеге турында үз фикерләрен әйтергә,үзе өчен һөнәри перспективаларны билгеләргә тиеш. Үзеңне презентацияләгәндә оештыру-педагогик эшчәнлектә катнашуның беренчел тәҗрибәсе, педагогик класс (булган очракта) эшендә, һөнәри осталык бәйгеләрдә, олимпиадаларда һәм педагогик компетенцияләр буенча чемпионатларда, волонтерлык хәрәкәтендә, Россия укучылар хәрәкәтендә һ.б.катнашу турында сөйләргә мөмкин. Катнашуның барлык формаларын документаль рәвештә (дипломнар, грамоталар, сертификатлар һ.б. белән) дәлилләргә тәкъдим ителә.

5. Үз-үзеңне һөнәри тәкъдим итү (презентацияләү) формасындагы сынауга керү паспорт нигезендә башкарыла.Чит кешеләр сынауларга кертелми. Керү сынавы нәтиҗәләре беркетмә (протокол) белән рәсмиләштерелә. Имтихан комиссиясе составына ДАҺБУ “Казан педагогика көллияте» нең ике мөгаллиме керә, аларның һәркайсы баллар санын үзе билгели, ә йомгаклау суммасы ике мөгаллимнең дә уртача баллары буенча билгеләнә.

Абитуриентның телдән сөйләменә мультимедия презентация һәм шәхси казанышлар портфолиосын тәкъдим итәргә киңәш ителә. Портфолио файллы папкада туплана. Портфолиода сертификатлар, грамоталар, дипломнар, характеристикалар һ. б. тәкъдим ителергә мөмкин.

Керү сынауларын үткәргәндә, абитуриентның үз-үзен тәкъдим итүе (презентацияләве) видеога төшерелә. Керү сынаулары 5 баллы система буенча бәяләнә.

**Инвариант өлешнең кабул итү сынавын бәяләү критерийлары: үз-үзеңне тәкъдим итү (презентацияләү)**

| Бәяләү критерийлары | 0 балл | 0,5 балл | 1 балл |
|---|---|---|---|
| Абитуриент педагогик юнәлештәге белгечлек сайлауны логик эзлеклелектә һәм ышанычлы итеп дәлилли, дөньяга карашын һәм педагогик әдәбият белән таныш булуын күрсәтә | | | |
| Абитуриент булачак педагогик һөнәри эшчәнлеге, аның киреклеге турында тирәнтен уйлана | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Абитуриент киләчәк карьерасын проектлый, үзен укытучы/тәрбияче буларак яхшы күз алдына китерә | | | |
| Абитуриент фикерләрен телдән һәм язма сөйләмдә ачык һәм эзлекле рәвештә аңлата.Телдән сөйләм барышында грамматик һәм орфоэпик хаталарга, язма сөйләм барышында (электрон презентациядә) грамматик, орфографик һәм пунктуацион хаталарга юл куймый. | | | |
| Абитуриентның сөйләме үзенчәлекле, эмоциональ; Әдәби сөйләм нормаларына туры килә; Сөйләм темпы, дикция, паузалар, интонацияләр, сүзсез чаралар (ишарәләр, мимика) дөрес һәм урынлы кулланыла. Сөйләм стиле рәсми аралашуга нормаларына туры килә | | | |

**Презентацияне эшләү өчен тәкъдимнәр**

**Презентациягә техник таләпләр**

| | |
|---|---|
| Презентация форматы | Microsoft PowerPoint, Adobe Premiere, Marcomedia Flash һ. б |
| Презентация вакыты | Презентация видео кисәкләрен, тавыш бизәлешен, фотоларны үз эченә ала (презентацияне күрсәтүнең гомуми вакыты 5 минуттан артык түгел). |
| Титул слайдын бизәү | Презентациянең титул слайдында автор турында мәгълүмат тупланылган булырга тиеш: абитуриентның ФИО, аттестат алган белем бирү оешмасының исеме, тәмамлау елы. |

**Презентация слайдларын бизәү**

| | |
|---|---|
| Стиль | Бердәм бизәү стилен саклагыз. Презентациядән читкә алып китә торган стильләрдән сакланыгыз. Ярдәмче мәгълүмат төп мәгълүматтан (текст, иллюстрацияләр |

| | |
|---|---|
| | белән) өстенлек итәргә тиеш түгел |
| Фон | Фон өчен салкын тоннар өстенлек итә |
| Төсләр куллану | Бер слайдта өчтән артык төс кулланырга киңәш ителми: берсе фон өчен, берсе атама , берсе текст өчен. Фон һәм текст өчен контраст төсләр кулланыгыз.<br>Гиперссылкаларның (кулланганга кадәр һәм аннан соңгы)төсенә игътибар итегез |
| Анимация эффектлары | Слайдта мәгълүматны күрсәтү өчен компьютер анимациясе мөмкинлекләрен кулланыгыз.<br>Төрле анимация эффектларын куллану белән артык мавыкмаска кирәк, алар слайдтагы мәгълүматның эчтәлегеннән игътибарны читкә юнәлтергә тиеш түгел. |

**Презентациядә мәгълүматны тәкъдим итү**

| | |
|---|---|
| Мәгълүмат эчтәлеге | Кыска сүзләр һәм җөмләләр кулланыгыз. Слайд атамасы ( исеме) аудитория игътибарын җәлеп итәргә тиеш. |
| Мәгълүматның биттә урнашуы | Мәгълүматның горизонталь урнашуы уңышлырак. Иң мөһим мәгълүмат экран үзәгендә урнашырга тиеш. Әгәр слайдта рәсем булса, язу аның астында булу әһәмиятле. |
| Шрифт | Атамалар өчен шрифтлар ким дигәндә 24. Мәгълүмат өчен ким дигәндә 18. Сызыксыз шрифтларны еракта уку җиңелрәк. Бер презентациядә төрле шрифтларны кулллану урынсыз. Мәгълүматны аерып чыгару өчен, калын шрифт, курсив яки ассызыклау кулланырга кирәк. Баш хәрефләрне артык кулланырга ярамый. |
| Мәгълүматны аерып алу ысуллары | Мәгълүматны аерып алу ысулларын рамкалар; чикләр кую; штриховка, уклар; иң мөһим фактларны күрсәтү өчен рәсемнәр, диаграммалар, схемалар. кулланырга кирәк. |

| | |
|---|---|
| Мәгълүмат күләме | Бер слайд артык күп мәгълүмат белән тутырылырга тиеш түгел: кешеләр берьюлы барлыгы өч факт, нәтиҗә, билгеләмәдән артык мәгълүматны истә калдыра алмыйлар.<br>Төп пунктлар һәрберсе аерым слайдта күрсәтелгәндә нәтиҗәлерәк булачак. |
| Слайдларның төрләре | Слайдтагы мәгълүматны текст, таблица, диаграмма төрләләре белән күрсәтү уңышлырак. |

**Портфолио структурасы**

Абитуриент портфолиосы титул бите һәм ике бүлектән тора.

*1 нче бүлек:* “Минем портретым”. Биредә абитуриент турында төп мәгълүмат бирелә, аларны теләсә нинди ысул белән тәкъдим итәргә мөмкин. Монда абитуриентның шәхси мәгълүматлары, шәхси фотолары булырга мөмкин.

*2 нче бүлек*: “Документлар портфолиосы”. Бу бүлектә сертификацияләнгән (документлаштырылган) белем өлкәсендә шәхси казанышлары тәкъдим ителә: олимпиадаларда, бәйгеләрдә, башка чараларда катнашу турында документлар (грамоталар, таныклыклар, дипломнар, сертификатлар һ.б.).

Өстәмә белем бирү учреждениеләре дипломнары, сертификатлары, уңышлар таблицасы, тест нәтиҗәләрен дә тәкъдим итәргә мөмкин.

6. Кабул итү сынавы нәтиҗәләре, аны тапшырганнан соң икенче көнне, сайтта һәм көллиятнең мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән игълан ителә

7. Керү сынавының вариатив өлеше белем бирү оешмасының ихтыяҗын исәпкә алып төзелә, белгечлек таләпләре буенча керүчеләрнең үзенчәлекләрен өйрәнү, шәхси юнәлешен билгеләү, иҗади сәләтләрен тикшерү, метапредмет күнекмәләренең формалашу дәрәҗәсен бәяләүне исәпкә алып башкарыла.

8. Әдәби-сәнгать әсәренең фрагментын уку һәм анализлау формасындагы иҗади бирем (5 минут дәвамында) индивидуаль рәвештә үткәрелә һәм имтихан комиссиясе әгъзаларының абитуриент белән актив телдән диалогын күздә тота. Диалог нәфис әдәбият әсәреннән алынган текст

фрагментының эчтәлеге буенча әңгәмә формасында төзелә. Сәнгать әсәренең фрагмент эчтәлеге рухи-әхлакый, патриотик, сәнгать-эстетик, һөнәри тәрбия юнәлешләренең берсен ачып бирергә мөмкин . Тәкъдим ителгән фрагмент нигезендә абитуриент үз карашын, фикерен белдерә. Сәнгать әсәренең эчтәлеге буенча билгеле бер аудиториягә юнәлдерелгән өч сорау формалаштыра.

Әдәби-сәнгать әсәренең фрагментын уку һәм анализлау формасындагы керү сынаулары барышы видеога төшерелә.

Керү сынаулары 5 баллы система буенча бәяләнә.

**Вариатив өлешнең кереш сынавын бәяләү критерийлары: әдәби-сәнгать әсәренең фрагментын уку һәм анализлау формасында иҗади бирем**

| Бәяләү критерийлары | 0 балл | 0,5 балл | 1 балл |
|---|---|---|---|
| Абитуриент әсәрнең идея-сәнгать эчтәлеген белә һәм аңлый | | | |
| Абитуриент вакыйгаларның үзара бәйләнешен, геройларның характерын һәм гамәлләрен аңлата белә | | | |
| Абитуриент әсәрнең эчтәлегенә автор тарафыннан салынган төп идеяләргә ярашлы рәвештә сәнгать әсәрен анализлый белә | | | |
| Абитуриент әдәби-сәнгать әсәрләрен интерпретацияли, үз фикерен дәлилли белә | | | |
| Абитуриент монологик әдәби сөйләмгә ия, куелган сорауларга логик, эзлекле җавап бирә һәм үзе әсәр эчтәлеге буенча билгеле бер аудиториягә сорау бирә белә | | | |

9. 44.02.01 “Мәктәпкәчә белем бирү”, 44.02.02 “Башлангыч сыйныфларда белем бирү” белгечлекләре буенча керү сынавы нәтиҗәләре биремнәрне үтәү нәтиҗәләре теркәлгән беркетмә (протокол) белән рәсмиләштерелә.

10. Инвариант һәм вариатив өлешләр нәтиҗәләре буенча керү сынауларының гомуми нәтиҗәсен билгеләү һөнәри белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль башкарыла. Абитуриентның гомуми баллар санын

белем турында документта яки белем һәм квалификация турында документта күрсәтелгән уртача балл һәм керү сынаулларында җыйган баллар суммасы кушу тәшкил итә.

**Абитуриентларның гомуми рейтингында катнашуның гомуми баллын якынча исәпләү:**

<table>
<tr><td colspan="2">Керү сынаулары өчен баллар.<br>Һәр сынау максимум 5 балл</td><td>Керү сынаулары өчен уртача балл (А+Б)/2<br>Максималь 5 балл</td><td>Белем турындагы документның уртача баллы Максималь 5 балл</td><td>Керүченең гомуми баллы Максималь 10 балл</td></tr>
<tr><td>1.Үз-узеңне тәкъдим итү (А)</td><td>5</td><td rowspan="2">4.5</td><td rowspan="2">4,6</td><td rowspan="2">9.1</td></tr>
<tr><td>2. Әдәби-сәнгать әсәренең фрагментын уку һәм анализлау формасында иҗади биремне үтәү (Б)</td><td>4</td></tr>
<tr><td>Йомгаклау баллары</td><td></td><td>4,5</td><td>4,6</td><td>9,1</td></tr>
</table>